**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 26 февраль № 118

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы һөнәр белеме бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентлары һәм укучылары тукलануының көндезге рационы кыйммәтен һәм Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән стипендия фондын формалаштыру өчен нормативлар билгеләү турында» 2014 ел, 29 октябрь, 808 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы һөнәр белеме бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентлары һәм укучылары тукलануының көндезге рационы кыйммәтен һәм Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән стипендия фондын формалаштыру өчен нормативлар билгеләү турында» 2014 ел, 29 октябрь, 808 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктның өченче – бишенче абзацларындагы «академик стипендиясе» сүзләреннән соң «, социаль стипендиясе» сүзләрен өстәргә;

карарга түбәндәге эчтәлекле яңа 2 – 4 нче пунктлар өстәргә:

«2. Ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга айлык социаль стипендия күләме «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнә дип тәгаенләргә.

3. Белем бирү оешмаларына инвалид балалар, I һәм II төркем инвалидлар, бала чактан инвалид булган студентларга, Чернобыль АЭСында һәлакәт һәм башка радиация һәлакәтләре аркасында, Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация тәэсиренә дучар булган студентларга, хәрби хезмәт узган чорда алган хәрби имгәнү яки авыру аркасында инвалидлар һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары булган йә дәүләт социаль ярдәмен алуга хокуклы студентларга, шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының эчке гаскәрләрендә, федераль башкарма хакимият органнары каршындагы инженер-техник, юл-төзелеш хәрби формированиеләрендә һәм гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итәргә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының коткару хәрби формированиеләрендә, Россия Федерациясенең Тышкы разведка хезмәтендә, федераль иминлек хезмәте органнарында, дәүләт сагы органнарында һәм Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының мобилизация әзерлеген тәэмин итүче федераль органда солдатлар, матрослар, сержантлар, старшиналар биләргә тиешле хәрби вазыйфаларда контракт буенча кимендә өч ел хезмәт иткән һәм хәрби хезмәттән «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 ел, 28 март, ФЗ-53 нче Федераль законның 1 нче пунктындагы «б» - «г» пунктчаларында, 2 нче пунктындагы «а» пунктчасында һәм 51 статьясындагы 3 нче пунктның «а» - «в» пунктчаларында күздә тотылган нигезләр буенча азат ителгән гражданнар арасындагы студентларга билгеләнә торган социаль стипендияләр күләмнәрен билгеләгәндә бу карарның 1 нче пунктында билгеләнгән тиешле нормативларга карата 1,5 арттыру коэффициентын куллануны тәкъдим итәргә.

4. Стипендияләр түләү белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга белем алучыларны стипендия белән тәэмин итүгә (стипендия фондына) бүлеп бирелә торган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.»;

карарның 2, 3 нче пунктларын шул ук эзлеклелектә 5, 6 нчы пунктлар дип санарга.

2. Бу карарның гамәле 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\118.doc